РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ БОЛЬШЕНЫРТИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422063, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Б.Нырты, ул. М Джалиля, д.13
тел. (84362) 45-2-32

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422063, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Нырты авылы, М Җәлил урамы, 13 йорт
тел. (84362) 45-2-32

e-mail: Bnir.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
24.09.2018 г. №13

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Нырты авыл җирлегендә гражданнардан үзара
салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле
референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында” 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Олы Нырты авыл җирлеге Советының 17.09.2018 №11 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитетының 21.09.2018 №22 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Олы Нырты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Завод Нырты авылы зиратларын карап тоту;
- Олы Нырты авылы зиратларын карап тоту;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.

ӘЙЕ ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Олы Нырты авыл җирлеге башлыгы Р.З.Сәфәргалиев